| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

19.05.2026 Казан ш № 405

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 18.04.2025 № 251 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе формасына (җаваплары контроль затның мәҗбүри таләпләрне үтәве яисә үтәмәве турында таныклык бирә торган контроль сораулар исемлеге) үзгәрешләр кертү турында

БОЕРЫК БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе (җаваплары контроль затның мәҗбүри таләпләрне үтәве яисә үтәмәве турында таныклык бирә торган контроль сораулар исемлеге) формасын раслау турында» 18.04.2025 № 251 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә төбәк дәүләт контроле (күзәтчелеге) кысаларында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан кулланыла торган тикшерү кәгазе формасына (җаваплары контроль затның мәҗбүри таләпләрне үтәве яисә үтәмәве турында таныклык бирә торган контроль сораулар исемлеге), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

13 пункт таблицасының «Мәҗбүри таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында:

3 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Рәсәй Хезмәт министрлыгының 2025 елның 28 мартындагы 163н номерлы «Күрсәтелгән мәгълүматның эчтәлегенә һәм бирү рәвешенә таләпләрне дә кертеп, социаль хезмәтләр күрсәтүче турында мәгълүматны урнаштыру һәм яңарту тәртибен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге социаль хезмәтләр күрсәтүченең рәсми сайтында раслау турында» боерыгы белән расланган (алга таба - Рәсәй Хезмәт министрлыгының 163н номерлы боерыгы белән расланган тәртип), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә социаль хезмәтләр күрсәтүче турында мәгълүмат урнаштыру һәм яңарту тәртибенең 1 пунктындагы 1, 3 – 6 пунктчалары»;

4 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Рәсәй Хезмәт министрлыгының 163н номерлы боерыгы белән расланган Тәртипнең 1 пунктының 7 – 8 подпунктлары;».

Министр Э.Ә. Зарипова